Республика Татарстан
Муниципальное образование город Арск
Арского муниципального района
Совет города Арск
422000, г. Арск, площадь Советская , 27
тел. 3-15-25, 3-16-25

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районының
Арча шәһәр муниципаль берәмлеге
Арча шәһәр Советы
422000, Арча шәһәре,Совет мәйданы, 27
тел. 3-15-25, 3-16-25

**Арча шәһәр Советы**
**КАРАРЫ**

**«22» ноября 2024 ел** **№ 138**

**«Җир салымы турында» 2022 елның 17 августындагы 79 номерлы Арча шәһәр Советы карарына (11.01.2023 №90, 29.11.2023 № 115, 17.09.2024 №135 үзгәрешләр белән) үзгәрешләр кертү хакында**

2024 елның 12 июлендәге 176-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге уставына таянып, Арча шәһәр Советы карар бирде:

1. «Җир салымы турында» 2022 елның 17 августындагы 79 номерлы Арча шәһәр Советы карарына (11.01.2023 №90, 29.11.2023 №115, 17.09.2024 № 135 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1) 2.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Әлеге абзацта күрсәтелгән шәхси торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган җир кишәрлекләреннән һәм һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә торган җир кишәрлекләреннән тыш, торак фонды һәм (яисә) торак-коммуналь комплексның инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән (торак фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексның инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган күчемсез мөлкәт объектына туры килә торган җир кишәрлегенең өлешеннән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата 0,1 процент.».

2. Әлеге карарның 1 пунктының гамәлдә булуы 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карар Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында рәсми басылып чыккан көннән кимендә бер ай узгач үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль мәсьәләләр буенча даими эшләүче комиссиягә йөкләргә.

«Арча шәһәре» муниципаль
берәмлеге башлыгы в.б.,
Арча шәһәр Советы рәисе в.б. Г.Х.Нигъмәджанова